| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЗАЙ-КАРАТАЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЗӘЙ-КАРАТАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2019 елның 15 октябре №29

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Зәй-Каратай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 17 ноябрендәге 50 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Зәй-Каратай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы яңа редакциядәге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 16_1 статьясына һәм нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 26 июлендәге 226-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының "Зәй-Каратай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 5 бүлеге нигезендә Зәй-Каратай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Зәй-Каратай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 17 ноябрендәге 50 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Зәй-Каратай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы яңа редакциядәге Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**4 бүлекнең 1 пунктындагы 5 пунктчасының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«Җирлек башкарма комитеты җитәкчесе һәм җирле үзидарәнең махсус вәкаләтле вазыйфаи заты яшәү урыны буенча яки тиешле җирлектә, торак пунктта теркәлгән затлар өчен түбәндәге нотариаль гамәлләр кылырга хокуклы:»;

**4 бүлекнең 1 пунктындагы 5 пунктчасының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;**

**4 кисәкнең 1 пунктындагы 5 пунктчасының 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«2) күчемсез милек белән идарә итүгә ышанычнамәләреннән тыш, ышаныч кәгазен раслау;»;

**4 кисәкнең 1 пунктындагы 5 пунктчасының 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«3) мирас милке исемлеген җитештерү юлы белән мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрү;»;

в) **4 бүлекнең 1 пунктындагы 5 пунктчасының икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«Россия Федерациясе закон актлары белән җирлек башкарма комитеты җитәкчесе һәм җирле үзидарәнең махсус вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан башка нотариаль гамәлләр башкару хокукы бирелергә мөмкин.»;

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә яңа редакциядә үзгәрешләр кертү хакында» карарны теркәү урынында теркәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Зәй-Каратай авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы, Совет рәисе М.И.Идиятова